СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**09.09.2016**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 127**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү инициативасын тәкъдим итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү, үз составына кергән торак пунктларны башка торак пунктлар территорияләренә кертүгә китермәгәндә һәм әлеге карарга кушымта буенча, аларның чикләрен билгеләү инициативасы белән чыгарга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, законда билгеләнгән тәртиптә, тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү турында халык фикерен ачыклауны тәкъдим итәргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә, ярдәм күрсәтергә.


4. Әлеге карарны 2016 елның 10 сентябренә кадәр Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 127 номерлы карарына кушымта




Условные обозначения

- граница Республики Татарстан
- граница Зеленодольского муниципального района
- границы муниципальных образований
- А-Б - смежная граница муниципального образования «поселок городского типа Нижние Вязовые» и Свияжского сельского поселения
- административные центры поселений
- населенные пункты
- территория Свияжского сельского поселения Зеленодольского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования «поселок городского типа Нижние Вязовые» Зеленодольского муниципального района
- территория муниципального образования «поселок городского типа Нижние Вязовые» Зеленодольского муниципального района, включаемая в состав территории Свияжского сельского поселения Зеленодольского муниципального района